**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Тимерлек авыл җирлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019нчы елның 11 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Совет урамы 58нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чуаш Тимерлеге авылы Үзәк урамы буенча 1-33нче йортлардан, Урман урамы буенча 1-10нчы, 1-14нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019нчы елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Үзәк урам, 3нче йорт адресы буенча урнашкан Тимерлек төп гомумибелем мәктәбе бинасында бинасында Татарстан Республикасы Чуаш Тимерлеге авылы Нурлат урамы 1-9нчы, Совет урамы 1-58нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2019нчы елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Совет урамы 58нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чуаш Тимерлеге авылы Совет урамы 59-99нчы, Совет тыкрыгы буенча 1-4нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Чуаш Тимерлеге авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча җитештерелергә тиеш.
5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 500 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- Чуаш Тимерлеге авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр башкару.
- Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт җәю.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов